КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 24 декабрь г.Казань № 1137

«Җәмәгать оешмаларының Татарстан Республикасында компакт яши торган халыклар телләрен саклау һәм үстерү буенча инициативаларына ярдәм» гранты һәм аны бирү тәртибе турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 10 сентябрь, 821 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Җәмәгать оешмаларының Татарстан Республикасында компакт яши торган халыклар телләрен саклау һәм үстерү буенча инициативаларына ярдәм» грантын гамәлгә куярга.

2. Бу карарга теркәлгән «Җәмәгать оешмаларының Татарстан Республикасында компакт яши торган халыклар телләрен саклау һәм үстерү буенча инициативаларына ярдәм» гранты һәм аны бирү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 24 декабрь, 1137 нче
карары белән расланды

«Җәмәгать оешмаларының Татарстан Республикасында компакт яши торган халыклар телләрен саклау һәм үстерү буенча инициативаларына ярдәм» гранты һәм аны бирү тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җәмәгать оешмаларына «Җәмәгать оешмаларының Татарстан Республикасында компакт яши торган халыклар телләрен саклау һәм үстерү буенча инициативаларына ярдәм» грантын (алга таба – грант) субсидияләр рәвешендә бирү максатын, шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Грант бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 10 сенябрь, 821 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру кысаларында гамәлгә ашырыла.

3. Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына грант бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык).

4. Әлеге Нигезләмәдә аннан файдалану максатлары өчен түбәндәге терминнар кулланыла:

грант алырга теләүче – законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән, грант алуга сайлап алу игълан ителгән датага кадәр кимендә бер ел Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашырган җәмәгать оешмасы;

грант алучы - грант алуга сайлап алуда җиңүче дип танылган, аңа карата грант бирү турында карар кабул ителгән грант алырга теләүче;

проект – вакыты ягыннан чикләнгән, Татарстан Республикасында компакт

яши торган халыклар телләрен саклау һәм үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чара.

5. Сайлап алуны үткәрү ысулы – грант бирү нәтиҗәләренә ирешүнең иң яхшы шартларыннан чыгып, грант алучыны билгеләүдән гыйбарәт конкурс.

Грант алучылар категориясе – законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән, грант алуга сайлап алу игълан ителгән датага кадәр кимендә бер ел Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген башкарган, проектны гамәлгә ашырырга планлаштырган җәмәгать оешмалары.

6. Грант бирүнең максаты – проектларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

7. Грант турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре-дәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – «Интернет» челтәре, бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://mon.tatarstan.ru) (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) урнаштырыла.

8. Сайлап алу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләр алучыларны сайлап алу башкарыла торган дәүләт мәгълүмат системалары турында» 2024 ел, 28 ноябрь, 1074 нче карары нигезендә https://subsidiya.tatar.ru/ яки https://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча «Минем субсидияләр» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – «Минем субсидияләр» системасы) гамәлгә ашырыла.

9. Министрлыкның һәм заявкаларны карау буенча конкурс комиссиясенең (алга таба – конкурс комиссиясе) грант алырга теләүчеләр белән үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» системасында электрон рәвештәге документлардан файдаланып гамәлгә ашырыла.

10. Грант алырга теләүчеләрнең «Минем субсидияләр» системасы функциясеннән файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

11. Грант бирү алымы – чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

12. Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә проектны гамәлгә ашыруга бәйле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү;

грант алучы хезмәткәрләренең, проектны гамәлгә ашыруны башкаручы чакырылган белгечләрнең хезмәте өчен түләү;

проектны гамәлгә ашыру белән бәйле элемтә хезмәтләре өчен түләү;

проектны гамәлгә ашыру белән бәйле транспорт хезмәтләре, командировка чыгымнары өчен түләү;

проектны гамәлгә ашыру максатларында кулланыла торган бүлмәләр

арендасы шартнамәләре буенча түләү;

проектны гамәлгә ашыру белән бәйле әйберләр кайтарту һәм хезмәтләр күрсәтү, эшләр башкару шартнамәләре буенча түләү;

грант алучының проектны гамәлгә ашыру белән бәйле педагогик хезмәткәрләренең һәм идарәче персоналының квалификациясен күтәрүне, һөнәри әзерлек узуын һәм аларның стажировкасын оештыру;

проектны гамәлгә ашыру белән бәйле авторлык заказы, авторлык хокукларын тапшыру шартнамәләре, махсус һәм интеллектуаль хокукларны куллану буенча лицензия шартнамәләре буенча түләү.

13. Грантның күләме 200,0 мең сум тәшкил итә. Ел саен иң күбе биш грант бирелә.

14. Грант бирү нәтиҗәләре:

проектны кимендә 50 кеше җәлеп итеп гамәлгә ашыру;

массакүләм мәгълүмат чараларында проектны гамәлгә ашыруны яктырту буенча кимендә өч басма урнаштыру.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срогы – грант бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

15. Заявканы карап тикшерү һәм килешү төзү датасына карата грант алырга теләүче түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

грант алырга теләүченең бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмый яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

грант алырга теләүченең башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмый (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

үзгәртеп оештыру (грант алырга теләүчегә башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процессы билгеләнәгән, грант алырга теләүченең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки грант алырга теләүченең баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар юк;

әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән максатка Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый.

16. Грант алырга теләүченең әлеге Нигезләмәнең 15 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерү «Минем субсидияләр» системасында сайлап алу үткәрүне тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары мәгълүматлары нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Грант алырга теләүче әлеге Нигезләмәнең 15 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәгән һәм «Минем субсидияләр» системасында тикшерү үтмәгән очракта, заявка кабул ителми.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Министрлыкның файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта, Министрлык грант алырга теләүченең әлеге Нигезләмәнең 15 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел (грант алырга теләүче әлеге документларны һәм мәгълүматны Министрлыкка үз инициативасы белән тапшырырга әзер булган очрактан тыш).

17. «Минем субсидияләр» системасында сайлап алу турында белдерү урнаштыру бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында грант турында мәгълүмат урнаштыру датасыннан соң гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуны үткәрү турында белдерү Министрлык тарафыннан, сайлап алуны үткәрү датасына кадәр 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда, «Минем субсидияләр» сервисында һәм Министрлыкның рәсми сайтында Министрлыкның җитәкчесе яки ул вәкаләт биргән зат тарафыннан үз кулы белән имза куелганнан соң һәм бердәм порталда субсидия турында мәгълүмат урнаштырылганнан соң бер календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

Министрлык, Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Минем субсидияләр»

системасында сайлап алуны үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру көненнән соң килә торган көннән алып өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган сайт бите турында, аны гамәлдән чыгару турында мәгълүмат, сайлап алу барышы һәм аның нәтиҗәләре турында мәгълүмат бастырып чыгара.

18. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү Министрлык тарафыннан «Минем субсидияләр» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формалары тутырылу юлы белән электрон рәвештә формалаштырыла, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда бастырыла, түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасы, шул ук вакытта заявкаларны кабул итүнең тәмамлану датасы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 нчы календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Нигезләмәнең 14 пункты нигезендә грант бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яки) битләре күрсәткечләре;

әлеге Нигезләмәнең 15 пунктында билгеләнгән, грант алырга теләүче әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән даталарга туры килергә тиеш булган грант алырга теләүчеләргә карата һәм грант алырга теләүче тарафыннан таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

грант алучылар категорияләре һәм заявкаларны бәяләү критерийлары;

әлеге Нигезләмәнең 26 һәм 27 пунктлары нигезендә заявкалар бирү тәртибе һәм заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләр билгеләнә торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

әлеге Нигезләмәнең 31, 32 һәм 41 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләре;

эшләп бетерү өчен заявкаларны кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кабул итмәү тәртибе, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 40 пункты нигезендә аларны кабул итмәү нигезләре турында мәгълүмат;

әлеге Нигезләмәнең кушымтасында билгеләнгән күрсәткечләр нигезендә бәяләү критерийларын, грант алырга теләүче тарафыннан һәр бәяләү критерие буенча кирәкле мәгълүматны, мондый мәгълүматны раслый торган белешмәләр, документлар һәм материалларны, заявкаларны бәяләү срокларын, шулай ук конкурс комиссиясенең һәм экспертларның заявкаларны бәяләүдә катнашуы яки катнашмавы турында мәгълүматны үз эченә алган заявкаларны бәяләү тәртибе;

әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән сайлап алу кысаларында бүленә торган грант күләме, сайлап алу нәтиҗәләре буенча грант бүлү кагыйдәләре һәм аны үткәрү нәтиҗәләре буенча сайлап алуда җиңүчеләр белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибе, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

грант алырга теләүчеләргә сайлап алуны үткәрү турында белдерү

нигезләмәләрен аңлату тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

грант алучы тарафыннан грант бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срок;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

бердәм порталда, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсен урнаштыру срогы (ул сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14нче календарь көннән дә соңрак була алмый).

19. Сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертү Министрлык тарафыннан, заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы башланудан да соңга калмыйча, әлеге Нигезләмәнең 18 пунктында каралган сайлап алуны үткәрү турында белдерүне формалаштыру тәртибе кебек үк тәртиптә, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

заявкалар бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән алып заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә 10 календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә сайлап алуда катнашучыларның заявкага үзгәрешләр кертү хокукы каралган нигезләмә кертелә;

заявка биргән грант алырга теләүчеләргә, «Минем субсидияләр» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.

20. Министрлык тарафыннан «Минем субсидияләр» системасында сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында белдерү урнаштыру грант алырга теләүчеләрнең заявкалар бирү срогы тәмамланган датага кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

21. Сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында белдерү «Минем субсидияләр» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаштырыла, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана (техник мөмкинлекләр булганда) яки алга таба кәгазьгә чыгару юлы белән машинкада җыю ысулы белән формалаштырыла, Министрлык җитәкчесе яки ул вәкаләт биргән зат тарафыннан үз кулы белән имзалана һәм сканердан чыгарыла, «Минем субсидияләр» системасында һәм Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла һәм сайлап алуны гамәлдән чыгару сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

22. Министрлык, табигый яки техноген һәлакәтләр, хәрби хәрәкәтләр, вәкаләтле орган тарафыннан гадәттән тыш дип танылган башка хәлләр белән бәйле рәвештә барлыкка килгән, җиңеп булмый торган вакыйгалар килеп чыккан очракта, сайлап алуны уздырмый.

23. Заявкалар биргән грант алырга теләүчеләргә «Минем субсидиядләр»

системасында сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында хәбәр ителә.

24. Сайлап алу «Минем субсидияләр» системасында аны үткәрүне гамәлдән чыгару турында белдерү урнаштырылган көннән гамәлдән чыгарылган дип санала.

25. Әлеге Нигезләмәнең 20 пункты нигезендә сайлап алуны үткәрмәү срогы тәмамланганнан соң һәм грант алырга теләүче белән килешү төзелгәнгә кадәр Министрлык Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә җиңеп булмый торган көч шартлары барлыкка килгән очракта гына сайлап алуны уздырмаска мөмкин.

26. Грант алырга теләүче сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән сроклар эчендә «Минем субсидияләр» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру һәм «Минем субсидияләр» системасына түбәндәге документларның электрон күчермәләрен (сканерлау юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) тапшыру юлы белән заявканы электрон рәвештә формалаштыра һәм бирә:

проектның актуальлеге һәм социаль әһәмияте, кадрлар һәм ресурслар белән тәэмин ителеше, проектның гамәли әһәмияте турында мәгълүматны, проектны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен, грант алырга теләүче эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгын/ачык булуын, фаразлана торган нәтиҗәләрне үз эченә алган проект тасвирламасы;

чыгымнар сметасы.

27. Заявкада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) грант алырга теләүче турында мәгълүмат һәм документлар:

грант алырга теләүченең тулы һәм кыскартылган исеме;

грант алырга теләүченең төп дәүләт теркәлү номеры;

юридик затның адресы;

элемтәгә керү өчен телефон номеры, юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен почта адресы һәм электрон почта адресы;

грант алырга теләүченең җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), салым түләүченең идентификация номеры, вазыйфасы);

грант алырга теләүче тарафыннан грант алырга теләүченең гамәлгә кую документлары нигезендә гамәлгә ашырырга хокуклы эшчәнлекнең төп һәм өстәмә төрләре исемлеге;

грантны күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук килешүне имзалауга вәкаләтле зат турында мәгълүмат;

б) грант алырга теләүченең сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган мәгълүмат һәм документлар;

в) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә грант алырга теләүче турында, аның тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүматны, шулай ук «Минем субсидияләр» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән бирелә торган тиешле сайлап алуга һәм грант бирү нәтиҗәсенә бәйле грант алырга теләүче турында башка мәгълүматны урнаштыру ризалыгын раслау;

г) грант алырга теләүче тарафыннан тәкъдим ителә торган грант бирү нәтиҗәсе, сорала торган грант күләме;

д) сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән заявкаларның һәр бәяләү критерие турында мәгълүмат, белешмәләр, документлар һәм мондый

мәгълүматны раслый торган материаллар.

28. Грант алырга теләүче заявканы сайлап алуны үткәрү датасына кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга, җитешсезлекләрне бетерергә һәм заявкалар кабул итү өчен билгеләнгән срок эчендә яңадан заявка бирергә хокуклы. Шул ук вакытта төзәтелгән заявка аларның кабат кергән көнендә заявкалар керү чираты тәртибендә теркәлә.

29. Заявкага үзгәрешләр кертү яки заявканы кире алу грант алырга теләүче тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 26 пунктында күрсәтелгән заявка формалаштыруның шундый ук тәртибендә грант алырга теләүче тарафыннан гамәлгә ашырыла.

30. Грант алырга теләүчеләр бердәм порталда сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән алып, заявкалар тапшыру тәмамланган көнгә кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка «Минем субсидияләр» системасында тиешле рәсми сорау формалаштыру юлы белән сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләрен аңлату турында иң күбе биш рәсми сорау җибәрергә хокуклы.

Министрлык, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән рәсми сорауга җавап итеп, әлеге белдерүдә билгеләнгән срок эчендә, әмма заявкалар бирү тәмамланган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча, «Минем субсидияләр» системасында тиешле аңлатма формалаштыру (техник мөмкинлекләр булганда) яки Министрлыкның электрон почтасы адресына кергән рәсми сорау өчен машинкада басыла торган, Министрлык җитәкчесенең яки аның вәкаләтле затының электрон имзасы белән имзалана торган җавап булдыру юлы белән сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Министрлык тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә бирелгән аңлатма әлеге белдерүдәге мәгълүматның асылын үзгәртергә тиеш түгел.

«Минем субсидияләр» системасында (техник мөмкинлек булганда) формалаштырыла торган аңлатманы, шулай ук әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә Министрлык тарафыннан электрон почта белән җибәрелгән аңлатманы карау мөмкинлеге барлык грант алырга теләүчеләргә «Минем субсидияләр» системасының гомуми файдалану урынында яки Министрлыкның рәсми сайтында грант алырга теләүчеләрдән кергән барлык рәсми сораулар һәм аларга җибәрелгән аңлатмалар урнаштыру юлы белән бирелә.

31. Министрлык заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү максатларында конкурс комиссиясе төзи, аңа республика башкарма хакимият органнары вәкилләреннән, Татарстан Республикасында компакт яши торган халыклар телләрен саклау, үстерү һәм аларның кулланылышы өлкәсендәге белгечләрдән, галимнәрдән, Министрлык каршындагы иҗтимагый совет әгъзаларыннан, җәмәгатьчелек вәкилләреннән кимендә биш әгъза керә. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең төбәк органнары вәкилләре саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми составының яртысыннан артмаска тиеш. Конкурс комиссиясе составы Министрлык боерыгы белән раслана.

32. Конкурс комиссиясе конкурс комиссиясе рәисеннән, рәис урынбасарыннан, сәркатибеннән һәм әгъзаларыннан тора.

Конкурс комиссиясенең эш тәртибе Министрлык боерыгы белән раслана.

33. Конкурс комиссиясе рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, конкурс комиссиясе карарын раслый.

Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда аның функцияләрен аның кушуы буенча конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе сәркатибе конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру функцияләрен башкара.

34. Конкурс комиссиясе карарлары конкурс комиссиясе утырышында катнашучы әгъзаларның күпчелеге тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

35. Сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, «Минем субсидияләр» системасында Министрлыкка, шулай ук конкурс комиссиясенә аннан файдалану мөмкинлеге бирелә.

Заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү «Минем субсидияләр» системасында Министрлыкка һәм конкурс комиссиясенә заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү өчен керү мөмкинлеге бирелгән көннән соң килә торган 15 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясе заявкаларны бәяләү критерийлары һәм аларның кушымтада билгеләнгән күрсәткечләре нигезендә бәяләүне гамәлгә ашыра.

36. Заявкаларны ачу беркетмәсе «Минем субсидияләр» системасында автомат рәвештә формалаштырыла һәм «Минем субсидияләр» системасында конкурс комиссиясе рәисенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана (техник мөмкинлекләр булганда) яисә кәгазь документ рәвешендә булдырыла һәм конкурс комиссиясе рәисенең үз кулы белән имзалана, алга таба «Минем субсидияләр» системасында сканердан чыгарылган күчермәсе урнаштырыла, шулай ук аңа имза куелган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда урнаштырыла.

37. Конкурс комиссиясе, сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән заявкаларны ачу көненнән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, заявкаларны ачу беркетмәсенә имза куя, анда сайлап алуда катнашу өчен кергән заявкалар турында түбәндәге мәгълүмат бирелә:

а) заявканы теркәү номеры;

б) заявка керү датасы һәм вакыты;

в) грант алырга теләүченең тулы исеме;

г) юридик затның адресы;

д) грант алырга теләүче тарафыннан сорала торган грант күләме.

38. Заявка, әгәр ул сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм әлеге Нигезләмәнең 40 пунктында күрсәтелгән заявканы кабул итмәү өчен нигезләр булмаганда, дөрес дип танылा.

39. Заявка, әлеге Нигезләмәнең 40 пунктында каралган заявканы кабул итмәү өчен нигезләр булган очракта, кабул ителми.

40. Заявканы кабул итмәү өчен нигезләр:

катнашучының әлеге Нигезләмәнең 15 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

грант алырга теләүче тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

грант алырга теләүче тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.

грант алырга теләүче тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе.

41. Заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү срогы тәмамланган көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, заявкаларны карап тикшерү беркетмәсе әзерләнә, анда кергән һәм карап тикшерелгән заявкаларның саны турында мәгълүмат, шулай ук һәрбер сайлап алуда катнашучы буенча аның заявкасын тиешле дип тану яки, кабул итмәү нигезләрен күрсәтеп, аның заявасын кабул итмәү турында мәгълүмат бирелә.

Заявкаларны карап тикшерү беркетмәсе «Минем субсидияләр» системасында автомат рәвештә формалаштырыла һәм «Минем субсидияләр» системасында конкурс комиссиясе рәисенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана (техник мөмкинлекләр булганда) яисә кәгазь документ рәвешендә булдырыла, конкурс комиссиясе рәисенең үз кулы белән имзалана, һәм Министрлык тарафыннан раслана. Заявкаларны карап тикшерү беркетмәсенең сканердан чыгарылган күчермәсе, аңа имза куелган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм «Минем субсидияләр» системасында урнаштырыла.

42. Сайлап алу түбәндәге очракларда уздырылмаган дип танyла:

а) заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

б) заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кабул ителмәгән.

43. Заявкаларны бәяләү критерийлары:

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар телләрен саклау һәм үстерү өчен проектның актуальлеге һәм социаль әһәмияте;

проектның кадрлар белән тәэмин ителеше;

проектның практик әһәмияте, аңа ихтыяҗ булу;

проектны гамәлгә ашыруның конкрет нәтиҗәсенең фаразлануы һәм аны кертүне бәяләү механизмы булу;

проектны гамәлгә ашыру чыгымнарын нигезләү;

проектны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре, аларның проект бурычларына туры килү-килмәве;

грант алырга теләүче эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгы / ачык булуы.

44. Кергән заявкаларны рангларга бүлү, алынган баллар саны тигез булган очракта, заявкаларны бәяләү йомгаклары буенча алынган баллар кимүгә һәм заявкалар керү чиратына карап гамәлгә ашырыла.

45. Сайлап алуны төгәлләү һәм сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү максатларында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе булдырыла. Йомгаклар ясау беркетмәсе «Минем субсидияләр» системасында автомат рәвештә формалаштырыла

һәм «Минем субсидияләр» системасында конкурс комиссиясе рәисенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана (техник мөмкинлекләр булганда) яисә кәгазь документ рәвешендә булдырыла, конкурс комиссиясе рәисенең үз кулы белән имзалана, Министрлык тарафыннан раслана һәм, имза куелган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча, «Минем субсидияләр» системасында һәм бердәм порталда, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләр билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла һәм түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявканың теркәлү номерын, заявканың керү датасын һәм вакытын, грант алырга теләүченең тулы исемен, юридик зат адресын, грант алырга теләүче тарафыннан сорала торган грант күләмен күрсәтеп, кергән һәм карап тикшерелгән заявкалар саны;

проект исеме;

заявкалары тиешле дип танылган һәм карап тикшерелгән грант алырга теләүчеләр турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән грант алырга теләүчеләр турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турында белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

заявкаларны бәяләү эзлеклелеге, заявкаларны бәяләүнең күздә тотылган һәр критерие буенча заявкаларга бирелгән күрсәткечләр, заявкаларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә мондый заявкаларга тәртип саннарын бирү турында кабул ителгән карар;

килешү төзелә торган грант алучыларның исеме һәм аларга бирелә торган грантның күләме.

46. Заявкаларны карап тикшерү беркетмәсенә һәм сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләрне кертү сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Нигезләмәнең 45 пунктында билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәләрнең яңа версияләрен формалаштыру юлы белән заявкаларны карап тикшерү беркетмәсенең һәм сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең яңа версиясенә имза куелган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

47. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча Министрлык тарафыннан грант алучылар белән, бердәм порталда сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе урнаштырылганнан соң 20 эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешү төзелә.

Килешү кәгазь документ рәвешендә һәр якның вәкаләтле затлары тарафыннан үз кулы белән имза куела торган ике нөсхәдә төзелә.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә грант бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Министрлыкка элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта, килешүгә килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча уртак фикергә ирешелмәгәндә килешүне өзү турында шарт кертелә.

Килешүгә грант алучының, грант алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар

предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан грант бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы кертелә.

Кирәк булганда Министрлык грант алучы белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

48. Грант алучы кушылу, кушу яки үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, өстәмә килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Грант алучы бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, шулай ук грант алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, грант алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган йөкләмәләр һәм грантның файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

49. Грант алучы, әгәр сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән сроклар эчендә грант алучы исеменнән эш итәргә хокуклы зат тарафыннан килешүгә кул кую тәэмин ителмәгән булса, килешү төзүдән баш тарткан дип танылa.

50. Грант алучы, шулай ук грант алучы белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алу тыела.

51. Министрлык, сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән килешүләр төзү тәгәлләнү срогы көненнән алып бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның боерыгы белән рәсмиләштерелә торган грант алучыга грант бирү турында яисә грант бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

52. Грант алучыга грант бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

грант алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

грант алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

53. Министрлык, грант бирү турында карар кабул ителгән көннән 10 нчы эш көненнән соңга калмыйча, акчаны грант алучы тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки Россия кредит оешмаларында ачылган исәп-

хисап яки корреспондент счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

54. Грант алучы кварталга кимендә бер тапкыр Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча грант бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

55. Министрлык әлеге Нигезләмәнең 54 пунктында күрсәтелгән хисапларны алар тапшырылган көннән алып биш эш көненнән артмаган срок эчендә тикшерүне башкара.

Килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүне һәм грант бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.

56. Министрлык грант алучының грант бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне башкара.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

57. Хисап финанс елында грантның файдаланылмый калган өлеше, килешүдә каралган очракларда, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Бирелгән грант Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәге рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – грант алучы тарафыннан грант биргәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылган очракта, шулай ук грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта;

максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган грант күләмендә – грант акчасыннан максатчан файдаланмау ачыкланган очракта;

58. Хисап финанс елында финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган акчаның файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә кире кайтарылырга тиеш (Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән тәртиптә әлеге акчаны файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш).

Хисап финанс елында файдаланылмаган акчаны әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән максатларга тоту ихтыяҗы булган очракта, грант алучы Министрлыкка, хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, шундый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Министрлык, грант алучыдан әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, агымдагы

финанс елында грантның хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗ булу яки булмау турында карар кабул итә.

Министрлык тарафыннан агымдагы финанс елында грантның хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен тотуга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык һәм грант алучы арасында мондый карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча килешүгә өстәмә килешү төзелә.

59. Әлеге Нигезләмәнең 57 һәм 58 пунктларында күрсәтелгән акча Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарылудан баш тартылган очракта, алар Министрлык тарафыннан эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

60. Грантны нәтиҗәле куллануны, аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшереп тору Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

«Җәмәгать оешмаларының Татарстан Республикасында компакт яши торган халыклар телләрен саклау һәм үстерү буенча инициативаларына ярдәм» гранты һәм аны бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымта

Заявкаларны бәяләү критерийлары

| Т/с | Заявкаларны бәяләү критерие исеме | Заявкаларны бәяләү критерийлары күрсәткечләре | Бәяләү крите-риеның авырлык күрсәт-кече, процент |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар телләрен саклау һәм үстерү өчен проектның актуальлеге һәм социаль әһәмияте | 0 – проектның актуальлеге һәм социаль әһәмияте нигезләнмәгән;<br>50 – сан һәм сыйфат күрсәткечләре күрсәтелмичә, гомуми фразалар бирелгән;<br>100 – проект юнәлдерелгән проб-лемалар җентекләп ачылган, аларның тасвирламасы аргументларга нигез-ләнгән һәм конкрет сан һәм (яки) сыйфат күрсәткечләре белән күрсәтелгән | 15 |
| 2. | Проектның кадрлар белән тәэмин ителеше | 0 – проект командасы турында, команда әгъзаларының квалифи-кациясе турында мәгълүмат юк;<br>20 – команда турында мәгълүмат бар, әмма команда әгъзаларының квали-фикациясе яки охшаш проектларны гамәлгә ашыру тәҗрибәсе турында мәгълүмат юк;<br>50 – команда, квалификация турында мәгълүмат бар, әмма команда әгъзаларының охшаш проектларны гамәлгә ашыру тәҗрибәсе юк;<br>100 – команда турында, команда әгъзаларының квалификациясе турында мәгълүмат бар, команданың | 20 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | барлык әгъзаларының охшаш проектларны гамәлгә ашыру тәҗрибәсе бар, раслый торган документлар теркәлгән | |
| 3. | Проектның практик әһәмияте, аңа ихтыяҗ булу | 0 – проект багышланган проблема җәмгыять тарафыннан таләп ителә торган разрядка керми, грант алырга теләүче тарафыннан нигезләнмәгән, грант бирү максатына туры килми;<br>30 – проект багышланган проблема грант бирү максатына туры килә, әмма җәмгыять тарафыннан таләп ителә торган разрядка керми, актуальлеге заявка бирүче тарафыннан нигезләнмәгән;<br>60 – проектны хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар грант бирү максатларына туры килә, актуаль проблемалар разрядына карый, әмма актуальлеге грант алырга теләүче тарафыннан нигезләнмәгән; проектны хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар гомуми фразалар белән, конкрет фактларга сылтама бирелмичә тасвирланган;<br>100 – проектны хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар грант бирү максатына туры килә, җентекләп ачылган, аларның тасвирламасы аргументланган һәм конкрет сан һәм (яки) сыйфат күрсәткечләре белән күрсәтелгән; проект тулысынча әһәмиятле дип билгеләнгән проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән; максатлы аудитория вәкилләре, потенциаль файда алучылар, партнерлар тарафыннан проблеманың актуальлеге расланган | 20 |
| 4. | Проектны гамәлгә ашыруның конкрет нәтиҗәсен фаразлау һәм аны гамәлгә кертүне бәяләү меха- | 0 – проектны гамәлгә ашыруның конкрет нәтиҗәсен фаразлау билгеләнмәгән, аның гамәлгә кертү механизмнары күрсәтелмәгән; | 10 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | низмы булу | 50 – проектны гамәлгә ашыруның конкрет нәтиҗәсен фаразлау билгеләнгән, аның гамәлгә кертү механизмнары күрсәтелмәгән;<br>100 – проектны гамәлгә ашыруның конкрет нәтиҗәсен фаразлау билгеләнгән, аның гамәлгә кертү механизмнары күрсәтелгән | |
| 5. | Проектны гамәлгә ашыру чыгымнарын нигезләү | 0 – проектны гамәлгә ашыруга каралган чыгымнар проект чараларына туры килми; проект бюджетында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 24 декабрь, 1137 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау һәм үстерү буенча иҗтимагый оешмалар инициативаларына ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турында нигезләмәнең (алга таба – грант турында нигезләмә) 12 пунктында каралган чыгымнар юнәлешенә карамый торган чыгымнарны грант исәбеннән гамәлгә ашыру каралган; проект бюджеты нигезләнмәгән;<br>40 – күздә тотылган чыгымнар проект чараларына туры килә, проект бюджетында грант турында нигезләмәнең 12 пунктында каралган чыгымнар юнәлешенә карамый; проект бюджеты нигезләнмәгән;<br>60 – күздә тотылган чыгымнар проект чараларына туры килә, барлык чыгымнар грант турында нигезләмә нигезендә чыгымнар юнәлешенә карый; проект бюджеты нигезләнмәгән;<br>100 – күздә тотылган барлык чыгымнар проект чаралары белән турыдан-туры бәйле; барлык чыгымнар грант турында нигезләмәнең 12 пунктында каралган чыгымнар юнәлешенә карый; проект бюджеты нигезләнгән | 20 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 6. | Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелегенең күрсәткечләре булу, алар проект бурычларына туры килү | 0 – гамәлгә ашыруның конкрет нәтиҗәләре, проектның нәтиҗәлелек күрсәткечләре билгеләнмәгән, аларны бәяләү критерийлары һәм ысуллары билгеләнмәгән, фараз күрсәткечләре юк;<br>50 – гамәлгә ашыруның конкрет нәтиҗәләре, проектның нәтиҗәлелек күрсәткечләре билгеләнгән, аларны бәяләү критерийлары һәм ысуллары, фараз күрсәткечләре конкретлаштырылмаган;<br>100 – гамәлгә ашыруның конкрет нәтиҗәләре, проектның нәтиҗәлелек күрсәткечләре билгеләнгән, аларны бәяләү критерийлары һәм ысуллары, фараз күрсәткечләре конкретлаштырылган | 10 |
| 7. | Грант алучы эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгы / ачык булуы | 0 – проектны яктырту буенча медиаплан юк. Проект эшчәнлеге турында мәгълүмат ачык чыганакларда бирелмәгән;<br>50 – гомуми медиаплан бар, әмма проект эшчәнлеге даими яктыртылмый (ел кварталына кимендә 1 тапкыр). Конкрет каналлар, форматлар һәм басмалар графиклары бирелмәгән;<br>100 – оешманың эшчәнлеге «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, массакүләм мәгълүмат чараларында системалы рәвештә яктыртыла. Сроклар, форматлар, тарату каналлары күрсәтелеп, җентекле медиаплан бирелгән | 5 |

---